■ Хәтирәләр

# Хаж - олы һынау

Флүрә һәм Дамир ӘХМӘҘИЕВТАР,
Учалы ҡалаһы



Ислам диненең бишенсе терәге булып хаж ҡылыу тора. Шуға күрә лә изге Ғәрәфә көнөндә Ер шарының төрлө тарафтарынан бихисап мосолман Мәккә ҡалаһына ағыла.

Беҙгә лә быйыл был ғибәҙәтте үтәү бәхете тейҙе. Наил хәҙрәт Исаканов менән өсәүләп юл сыҡтыҡ. Баш ҡаланан Төркиәгә һәм артабан Иорданияға самолет менән осторҡ. Ә Мәҙинә менән Мәккәгә автобуста алып барҙылар. 18 ноябргә барып еттек. Беҙҙең етәксебеҙ Тулҡын хәҙрәт булды. Ул дәрестәр үткәреп, хаж ғәмәлдәрен барыһы ла дөрөҫ итеп ҡылһын өсөн бик тырышты. Уға бик рәхмәтлебеҙ.

Юлдан һуң бер аҙ ял иткәс, изге “Әл-Хәрәм” мәсетенә барып сәләмләү тәүәфе ҡылдыҡ (Ҡәғбәтулланы ете тапҡыр урап сығыу). Ике рәҡәғәт намаҙ уҡығандан һуң, зәм-зәм һыуын туйғансы эсеп, Аллаһы Тәғәләнән еңеллек, йәнгә һәм тәнгә шифа һорап, доға ҡылдыҡ.

Әс-Сафа һәм Әл-Мәрүә тауҙары араһы 800 метр икән. Ҡаяташтан торған әллә ни бейек булмаған үрҙәр. Борон заман Хәжәр кескәй Исмәғил улы өсөн һыу эҙләп, ошо тау араһын ете тапҡыр урай. Шул саҡ Исмәғилдең аяҡ тибеп тыпырсынған урынынан шишмә ағып сыға. Һыуы йомшаҡ һәм тәмле.

Мәккәлә алты көн торғандан һуң, меңәрләгән палаткаларҙан торған Мина ҡасабаһына йүнәлдек. Уңайлы шарттар булдырылған палаткаларҙа 7 миллион самаһы кеше йәшәне! 26 ноябрь иртә менән Ғәрәфә тауына йүнәлдек. Көн оҙоно ошо тауҙа доға ҡылдыҡ. Был тауҙа Әҙәм (ғ.һ.с.) Һауа менән осрашҡан була. Аллаһы Тәғәләнән ярлыҡау һорап, Уға доға ҡылдыҡ. Үҙебеҙгә генә түгел, илебеҙгә, Башҡортостаныбыҙға, туғандарыбыҙға, дин ҡәрҙәштәребеҙгә, бөтә Учалы халҡына бәрәкәт биреүен һорапныҡ. Аҙаҡ Ғәрәфәнән Мөздәлифә үҙәненә килдек, унда аҡшам, йәстү намаҙҙарын уҡыныҡ. Икенсе көнгә Мина ҡасабаһына ҡайтып, ҡорбан салып, өйлә намаҙын уҡығандан һуң, шайтанға таш ата торған махсус урынға йүнәлдек. Заманында Исмәғилде (ғ.һ.с.) шайтан, атайың һине ҡорбан салырға алып бара, тип ҡотортоп маташҡан була бит. Ә Исмәғил (ғ.һ.с.) уны таш бәреп ҡыуа. Беҙ ҙә Мөҙдәлифәнән 49 ваҡ таш йыйып килтергәйнек, йола буйынса етеһен Ҡорбан ғәйетендә ырғыттыҡ. Унан һуң тырнаҡсәстәрҙе киҫеп, 9 саҡырым алыҫлыҡтағы “Әл-Харам” мәсетенә килдек. Тағы ла тәүәф ҡылып, ике рәҡәғәт намаҙ уҡып, зәм-зәм һыуын ауыҙ итеп, Әс-Сафа һәм Әл-Мәрүә араһында доға ҡылырға юл тоттоҡ. Аҙағынан Минаға барып, ҡалған таштарҙы бәреп (үрҙә тәүге 7 таш тураһында яҙҙыҡ инде), ғәмәлдәребеҙҙе тамамланыҡ. 1 декабрҙә Мөхәммәт пәйғәмбәрҙең (ғ.һ.с.) ерләнгән урынына барҙыҡ. Үҙе менән йәнәш ике сәхәбәһе - Ғүмәр раҙиаллаһу һәм Әбү Бәкер Ситдиҡ ерләнгән. Зыярат эргәһенән юл үтә, унан халыҡ йылға булып ағыла тиерһең. Фанатизмға бирелеп, илап-һыҡтап, ҡәберлектең алтын рәшәткәләрен кимереүселәр ҙә булманы түгел... Ә бындағы мәсет шул тиклем яҡты һәм ҙур, миллионлап кеше намаҙ уҡый. Эсенә һыймағандар тышта ғына ғибәҙәт ҡыла. Әйткәндәй, тышта ла балаҫтар йәйелгән, бик эҫе булғас, намаҙ уҡығанда ҡояштан ҡаплау өсөн ҙур зонттар асыла. Был ҡоролмалар һуңғы дәүерҙә генә ҡуйыла, үҙҙәре бик матур итеп яһалған. Ғөмүмән, Мәҙинәнең тышҡы ҡиәфәте лә, кешеләренең яғымлылығы ла күңелгә ныҡ хуш килде. Мәккә лә бик матур.

Шулай ҙа беҙҙең тарафтағы тәбиғәт унда юҡ инде. Тауҙар яланғас, ҡом-таш, иҫ киткес эҫе. Ғәрәптәр бик тырыш халыҡ икән, шундай шарттарҙа ла ағас-сәскә, йәшелсә үҫтерәләр. Үҙебеҙҙең йәшел хәтфә булып ятҡан болондар, күл-йылғалар, урмандар ирекһеҙҙән йыш иҫкә алынды. Ҡәҙерен беләйек!

7 декабрҙә Өфөгә, һуңынан үҙебеҙҙең Учалыбыҙға ҡайтып еттек. Иҫән-һау ҡайта алғаныбыҙға шатбыҙ, хажыбыҙ ҡабул булһын, тип теләнәбеҙ. Хаж - һынау ул. Ҡабул булһын өсөн күркәм холоҡ та, ғилем дә, йөрәк сафлығы ла берсә талап ителәә. Яҡташтарға шуны теләйһе киләә: хаж ҡылырға тырышығыҙ, иманығыҙ ныҡыныр.

# Пәйгамбәргә мәхәббәт тәрбиялик

Галимә ГАБДУЛЛИНА,
укытучы

Тагын бер рабигуль-әүвәл ае тарихка кереп бара. Сөекле пәйгамбәребезнең туган ае буларак, күңелдә зур урын алган бу ай, быел республикабызда тагын да җанлырак, эчтәлеклерәк үтте. Мәчет һәм мәдрәсәләрдә, мәдәният йортларында, гаилә дуслары белән оештырылган табыннарда Коръән аятьләре укылды, рәсүлебезнең кешелек доньясында тоткан урыны, аның тормыш юлы, пәйгамбәрлек вазыйфасы, яшәү үрнәге хакында вәгазьләр сөйләнде, мөнәҗәтләр җырланды, фильмнар күрсәтелде...

Иң куанычлысы шул, мондый кичәләрдә студентлар, мәктәп балалары да бик теләп катнашты. Аларның йөзләрендә динебезгә, Аллаһы Тәгаләгә, аның рәсүленә ихлас мәхәббәт нурлары чагылуын күрү өмет уята.

Әйе, Раббыбызга хисапсыз шөкерләр булсын, дистәләгән еллар дәвам иткән торгынлыктан дини асылыбызга борылдык. Диннән башка, Аллаһы Тәгалә кушкан рәвештә яшәүдән башка юллар кешелекне бары тик бәхетсезлеккә, матди бөлгенлеккә, рухи түбәнлеккә китергәнен үз күзләребез белән күреп торабыз. Без генә түгел, җир галәменең һәрбер почмагында бу хакыйкатьне меңнәр-миллионнар төшенде. Мөселманнар санының ике миллиардка якынлашуы да шуның ачык дәлиле түгелме?!

Инде үзебезнең илгә килик. Гаиләләребез таркалу җитмеш процентан узды, эшсезлек, азгынлык кебек күренешләр хакында сөйләп торасы да юк. Ә бит килеп туган рухи һәм матди торгынлыктан чыгу юлы бары тик Аллаһы Тәгаләнең хак рәсүле өйрәтеп калдырган Коръән кушканча яшәү юлы. Моны инде доньяның күп илләрендә күптән аңлый башладылар. Европа илләрендә мәчетләр санының бездәгедән дә артып китүе шул хакта сөйләмиме?

Тагын тарихка күз салыйк. Ундүрт гасыр элек Гарәбстан ярымутравы нинди хәлдә иде? Кәгъбәтуллаһ эченә йөзләрчә пот куеп ширек кылган, кыз балаларын терелә й күмгән, шәраб диңгезендә йөзеп эчкечелеккә чумган илбасарлар иле. Мөхәммәд салләллаһу гәләйһи вәсәлләм килеп, 23 ел пәйгамбәрлек вазыйфасын үтәгәннән соң бу халык кешелек доньясын үзенә иярттә алырлык дәүләт корды, әхлаклылыкның югары дәрәҗәсенә күтәрелде.

Гарәб халкын да, кешелек доньясын да караңгылыктан яктылыкка алып чыгучы, унсигез мең галәмгә рәхмәт итеп җибәрелүче сөекле пәйгамбәребезнең үрнәген, аңа мәхәббәтне байрак итеп без дә ватандашларыбызны ике доньяда бәхетле булу дәрәҗәсенә ирештерә алырбызмы? Аллаһы Тәгаләгә таянсак, Аңа буйсынсак, Аның илчесенә иярсәк, иншәә Аллаһ, булдырырбыз.

Моның өчен һәммәбезгә Аллаһы рәсүленең тормыш юлын җентекләп өйрәнергә, һәрбер гамәлдә аңа ошарга тырышу сыйфатын тәрбияләргә кирәк. Иң мөһиме: яшьләребез, балаларыбыз күңелендә аңа карата мәхәббәт ялкынын кабызып җибәрә алырлык очкын салу.

Мин үзем, мәсәлән, унике - унөч яшьләр чагымда әниемнең сөекле рәсүлебезнең бала чагы хакында күз яшьләре белән сөйләгәнен әле дә тәэсирләнеп искә алам. Ә инде картәтиемнең миңа яздырган догасын әле булса гаҗәпләнеп тә, әсәрләнеп тә кабатлыйм: “Иләәһи! Хәбиби Әкрамың хөрмәтенә без гасыйларга тәүбә - тәүфикъ биреп, ахыргы сулышыбызда иманыбызны юлдаш кылып, кыямәт көнендә сөекле рәсүлеңнең өммәтендә терелтеп, Үзеңнең рәхмәтеңә, ризалыгыңа ирештер. Фирдәвес җәннәте әһелләреннән кылып, Үзеңнең дидарың белән Хәбибеңнең дидарын даими күрүне насыйп әйлә”.

Моннан кырык еллар чамасы элек догалар дәфтәремдә язылып куелган шушы сүзләрне кабатлаган саен якыннарымның рәсүлебезгә булган чиксез мәхәббәте күңелдә яңара, бала чакта пәйгамбәребезгә карата салынган ихлас сөю орлыклары күз яшьләре булып бәреп чыга.

Шушы мәхәббәтне укучыларыма, ватандашларыма тулы килеш җиткерергә насыйп әйлә, Раббым, дип догалар кыламын.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рабиғүл ахыр 2010 миләди йыл**
**1431 һижри йыл.**

| Рабиғүл әүүәл, Рабиғүл ахыр | Аҙна көндәре | Март Апрель | Иртәнге намаҙ | Ҡояш ҡалка | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. намаҙы | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 30 | Шишәмбе | 16 | 6.00 | 7.30 | 13.30 | 17.51 | 19.21 | 20.51 |
| 1 | Шаршамбы | 17 | 5.57 | 7.27 | 13.30 | 17.53 | 19.23 | 20.53 |
| 2 | Кесе йома | 18 | 5.55 | 7.25 | 13.30 | 17.55 | 19.25 | 20.55 |
| 3 | Йома | 19 | 5.52 | 7.22 | 13.30 | 17.57 | 19.27 | 20.57 |
| 4 | Шәмбе | 20 | 5.50 | 7.20 | 13.30 | 17.59 | 19.29 | 20.59 |
| 5 | Йәкшәмбе | 21 | 5.47 | 7.17 | 13.30 | 18.01 | 19.31 | 21.01 |
| 6 | Дүшәмбе | 22 | 5.45 | 7.15 | 13.30 | 18.03 | 19.33 | 21.03 |
| 7 | Шишәмбе | 23 | 5.42 | 7.12 | 13.30 | 18.05 | 19.35 | 21.05 |
| 8 | Шаршамбы | 24 | 5.39 | 7.09 | 13.30 | 18.07 | 19.37 | 21.07 |
| 9 | Кесе йома | 25 | 5.37 | 7.07 | 13.30 | 18.09 | 19.39 | 21.09 |
| 10 | Йома | 26 | 5.34 | 7.04 | 13.30 | 18.11 | 19.41 | 21.11 |
| 11 | Шәмбе | 27 | 5.32 | 7.02 | 13.30 | 18.13 | 19.43 | 21.13 |
| ЙӘЙГЕ ВАҠЫТ | | | | | | | | |
| 12 | Йәкшәмбе | 28 | 6.29 | 7.59 | 14.30 | 19.15 | 20.45 | 22.15 |
| 13 | Дүшәмбе | 29 | 6.27 | 7.57 | 14.30 | 19.17 | 20.47 | 22.17 |
| 14 | Шишәмбе | 30 | 6.24 | 7.54 | 14.30 | 19.19 | 20.49 | 22.19 |
| 15 | Шаршамбы | 31 | 6.22 | 7.52 | 14.30 | 19.21 | 20.51 | 22.21 |
| 16 | Кесе йома | 1 | 6.19 | 7.49 | 14.30 | 19.22 | 20.52 | 22.22 |
| 17 | Йома | 2 | 6.17 | 7.47 | 14.30 | 19.24 | 20.54 | 22.24 |
| 19 | Шәмбе | 3 | 6.14 | 7.44 | 14.30 | 19.26 | 20.56 | 22.26 |
| 19 | Йәкшәмбе | 4 | 6.12 | 7.42 | 14.30 | 19.28 | 20.58 | 22.28 |
| 20 | Дүшәмбе | 5 | 6.09 | 7.39 | 14.30 | 19.30 | 21.00 | 22.30 |
| 21 | Шишәмбе | 6 | 6.07 | 7.37 | 14.30 | 19.32 | 21.02 | 22.32 |
| 22 | Шаршамбы | 7 | 6.04 | 7.34 | 14.30 | 19.34 | 21.04 | 22.34 |
| 23 | Кесе йома | 8 | 6.02 | 7.32 | 14.30 | 19.36 | 21.06 | 22.36 |
| 24 | Йома | 9 | 5.59 | 7.29 | 14.30 | 19.38 | 21.08 | 22.38 |
| 25 | Шәмбе | 10 | 5.57 | 7.27 | 14.30 | 19.40 | 21.10 | 22.40 |
| 26 | Йәкшәмбе | 11 | 5.54 | 7.24 | 14.30 | 19.42 | 21.12 | 22.42 |
| 27 | Дүшәмбе | 12 | 5.52 | 7.22 | 14.30 | 19.44 | 21.14 | 22.44 |
| 28 | Шишәмбе | 13 | 5.49 | 7.19 | 14.30 | 19.46 | 21.16 | 22.46 |

■ Укучыларыбыз иҗаты

# НӘРСӘ УЛ - БӘХЕТ?

Фәүзия ЗАҺИТОВА

*Бәхетлемен иманым көчле булганга,*
*Имандашлар белән һаман гыйлем алганга.*
*Бәхет, димен, мәчетләргә барып, намаз укып,*
*Бер Аллаһы Тәгаләгә генә инанганга.*

*Бәхет бит ул үзе килми кешеләргә,*
*Уйлап кара, үзең эзлә, бәндәм!*
*Укы Коръән, намаз укы, ураза тот.*
*Болар бәхет түгелмени, бәндәм?*

*Бәхет, димен, таһәрәт алып, госел коенуны,*
*Бәхет, димен, кояш чыкканчы намаз укуны,*
*Бәхет, димен, иртән якты доньяны күрүне,*
*Һәм көне буе күтәренке күңел белән йөрүне.*

*Бәхет, димен, төн менән көн алмашынуын,*
*Кояш чыгып көннең яктыруын.*
*Бәхет, димен, аяз көнне болыт чыгып,*
*Җир өстенә җылы яңгыр явуын...*

*Уйлап кара, бәндәм, болар барда - бәхет.*
*Кайдан килә, кемнәр бирә бу бәхетне сиңа?*
*Ныклап фикерләсән, табырсың син җавап:*
*Бу бәхетне безгә Аллаһы Тәгалә бирә.*

*Сора бәндә Аллаһыдан мохтаҗыңны,*
*Ул бит саран түгел, сорасаң бирә.*
*Яңгырын да бирә, җылысын да, яктылык та,*
*Әгәр ышанмасаң бер Аллаһка, газабын да.*

*Иртән торсак, аяк-кулларыбыз йөри.*
*Күзебез күрә, колакларыбыз ишетә.*
*Шөкер итеп яшибез Аллаһының биргәненә.*
*Үзе зур бәхет - йөгереп йөреп көнебез үтә.*

*Уфтанырга, сыкранырга вакытыбыз юк,*
*Ашап-эчеп, өй җыештыруга өйлә җитә.*
*Өйләне укыгач магазинга барып кайтабыз,*
*Кичке ашны әзерләгәнче икенде җитә.*

*Бәхет бит ул - эшләр беткәч Коръән уку,*
*Бәхет бит ул - икенде укыгач ахшамны көтү.*
*Шулай итеп көн үтеп тә китә.*
*Ястү белән витр вәҗип намазлары җитә.*

*Эшләр бетә, намазлар укылган.*
*Шатлык белән төнгә җитәбез.*
*Төннәр озын, йокы туя, төнлә торып,*
*Нәфел намазлары укып үтәбез.*

*Бәхет түгелме ни, имандашлар,*
*Уйлап кара, кемгә тия бу бәхет.*
*Мөселманнар саф күңелле, иманлылар,*
*Бер-берсенә ярдәмчеләр - бу бит үзе зур бәхет.*

*Бәхетлемен мөселманча яшәвемә,*
*Олы яшьтә гыйлем алып йөргәнемә.*
*Коръән укыйм тәҗвид белән,*
*нәхү-сарыфны өйрәнәм,*
*Сөенәмен Аллаһының биргәненә.*